СОВЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район, п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы, Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 354 от 29.04.2020

на № __от ________

# К А Р А Р

Саба муниципаль районы Советының 2018 елның 31 августында кабул ителгән 253 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазифаи тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, “Коррупциягә каршы тору турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

**1.** Саба муниципаль районы Советының “Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазифаи тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турындагы Нигезләмәне раслау турында” 2018 елның 31 августында кабул ителгән 253 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазифаи тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1.** Нигезләмәнең 2.1. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2.1. Комиссия составы Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

Комиссия комиссия рәисеннән, комиссия рәисе урынбасарыннан, секретарьдан һәм комиссия әгъзаларыннан тора. Комиссиянең барлык әгъзалары да карарлар кабул иткәндә тигез хокукларга ия. Комиссия рәисе булмаганда, аның вазыйфаларын комиссия рәисе урынбасары башкара.”.

**2.** Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

**3**. Әлеге карарның гамәлдә булуын 2018 елның 31 августыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга.

**4**. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р. Н. Минниханов